**Кукмара муниципаль районы**
**Байлангар авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**2022 елның «06» декабре** **№ 37**

**Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 23 ноябрендәге 2 номерлы Байлангар авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Уставы нигезендә Байлангар авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елның 18 декабренә 10 сәгать 00 минутка беренче этап, 2022 елның 18 декабренә 14 сәгать 00 минутка икенче этап «Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 23 ноябрендәге 2 номерлы Байлангар авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 23 ноябрендәге 2 номерлы Байлангар авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пунктта:

а) беренче абзацта " 950 сум» сүзләрен «1600 сум»сүзләренә алмаштырырга

б) киләсе эчтәлеккә яңа абзац өстәргә:

- Байлангар авылы мәдәният йортына мебель, тамашачылар залы өчен урындыклар, музыка һәм спорт инвентарьлары сатып алу һәм урнаштыру, пәрдәләр, челтәрләр, сәхнә һәм театр пәрдәләре сатып алу һәм урнаштыру ( проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру, килешү буенча түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Байлангар авыл җирлеге башлыгы: И.Ф. Кәримуллин